– тексттан сүзләрне, сүзтезмәләрне, гади җөмләләрне күчереп язу;

– үрнәк буенча бәйрәмгә чакыру язу;

– үрнәк буенча дустыңа хат язу;
– сөйләм бурычын аңлап, кыскача үз фикереңне язмача белдерү.
– текстның эчтәлеге буенча сорауларга язмача җавап бирү;
– терәк сүзләр ярдәмендә кечкенә хикәя төзеп язу;

**4 нче сыйныф**

**Укытуның шәхескә кагылышлы нәтиҗәләре**

– туган җир, Ватан төшенчәләре, үз культураң аша дөнья культурасына карата ихтирам тәрбияләү, аны өйрәнү теләге формалаштыру;
– үзлегеңнән белемеңне арттыру һәм үз-үзеңне тәрбияләү нигезендә, үз эшчәнлегеңне оештыра алу осталыгын формалаштыру;
– әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;
– әдәби әсәрләрдәге төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомумкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирә белү.

- туган илгә карата хөрмәт һәм мәхәббәт, горурлык хисләре тәрбияләү; үзеңне күпмилләтле Рәсәй дәүләтенең бер гражданы итеп тою; Россия гражданинына хас сыйфатлар булдыру, Туган илне ярату һәм ватанпәрвәрлек кыйммәтләрен кабул итү;
- дөньяда яшәүче барлык халыкларның карашларына, мәдәниятенә, теленә, диненә, гражданлык позициясенә аңлы рәвештә хөрмәт белән карау; башкалар фикерен хөрмәт итә һәм аларны тыңлый белү;
- гаилә әгъзаларына, гаилә кыйммәтләренә ихтирам һәм хөрмәт белән карау; башкаларның хис -кичерешләрен аңлау, аларга карата мәрхәмәтлелек һәм киң күңеллелек күрсәтә белү;үзеңнең һәм башкаларның холкына, тотышына әхлак нормалары югарылыгыннан бәя бирү;

**Метапредмет нәтиҗәләре**

**Укучылары өйрәнә:**

**Танып белү нәтиҗәләре**:

- **АРАЛАШУ ҺӘМ ТАНЫП-БЕЛҮ БУРЫЧЛАРЫН ХӘЛ ИТҮДӘ ТӨРЛЕ СӨЙЛӘМ ЧАРАЛАРЫН АКТИВ КУЛЛАНУ;**

– фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү;
– иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм төзи белү;
– объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгели белү;
– төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү.

- танып белү һәм коммуникатив бурычларны чишү өчен, төрле мәгълүмати чаралардан, аерым алганда, энциклопедияләр, сүзлекләр, белешмәләрдән һәм башка чыганаклардан файдалана белү;
- әңгәмәдәшеңне (укытучыны, сыйныфташыңны) тыңлау: әйтелгән фикерне кабатламау, башкалар әйткән фикерне тулыландыру;
- яраткан язучың турында әйтә белү һәм аның әсәрләрен атау, аларның эчтәлеге турында кыскача гына әйтә белү;
- әсәрнең төп темасын һәм фикерен (укытучы ярдәме белән) аерып чыгару;
- әсәрдәге геройларга (исемнәрен атау, портреты, сөйләме) һәм аларның гамәлләренә бәя бирү;
- сүзләрнең мәгънәсен ачыклау өчен аңлатмалы сүзлекбелән эшли белү;
- шигъри әсәрләрнең үзенчәлекләрен белү (ритм, рифма һ.б), жанр үзенчәлекләрен аеру ( халык авторлар иҗат иткән әкиятләр),әдәби алымнарны тану

(чагыштыру, сынландыру, каршы кую һ.б.)
- халык авыз иҗаты әсәрләрен авторлык әсәрләреннән аера белү;
- авторлар иҗат иткән әсәрләрдә тел-сурәтләү чараларын таба һәм атый белү( чагыштыру, сынландыру, гипербола, каршылык, фигуралар, кабатлау)
-дәреслектә / укый торган китапта бирелгән шартлы билгеләрне укый белү,кирәкле текстны китапның “Эчтәлек” бүлегеннән карап таба белү;
-- текстның билгеләнгән һәм кирәкле өлешләрен, юлларын, сүзтезмәләрен, сүзләрен бик тиз таба белү;
-- мәгълүмат алуның берничә чыганагы белән берьюлы эшли белү ( уку китабы, мөстәкыйль эшләү өчен эш дәфтәре һәм хрестоматия; уку китабы һәм сүзлекләр; текстлар һәм текстка иллюстрацияләр);
-- геройга карта авторлык мөнәсәбәтен ачыклау;
-- әсәрләрнең геройларына характеристика бирү, төрле әсәрләрнең берничә геройларының характерларын чагыштыру;
- китап һәм аның элементларында җиңел ориентлашу ( автор, исеме, эчтәлеге, иллюстрацияләр)
- әдәбиятның – сәнгатьнең бер чарасы буларак үсеш юнәлешен күзаллау: халык авыз иҗатыннан авторлар иҗат иткән әсәрләргә кадәр үткән араны аңлау;
- текст белән иркен эшләү: мәгълүматны аера белү, язучы әйтергә теләгән фикерне тотып алу, аны аңлату, кирәк очракта фикереңне үзгәртә белү;
-- өйрәнә торган дәреслек, башка уку комплектлары, сүзлекләр, вакытлы матбугат , мәктәп китапханәсе фонды белән иркен эшләү, кирәкле мәгълүматны бик тиз табу һәм аны белем алу максатында дөрес файдалана белү;
-- мәгълүмат алуның төрле чыганаклары белән иркен эшләү(әдәби текстлар, музыка һәм рәсем сәнгате әсәрләре)

**Регулятив нәтиҗәләр:**

– уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү, ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләр формалашу;
- әдәби әсәрне аңлап уку күнекмәләрен үзләштерү һәм куелган максат-бурычлардан чыгып, чагыштыру, анализ-синтез, гомумиләштерү, бәйләнеш сәбәпләрен билгеләп әсәр эчтәлеге буенча фикерләү нәтиҗәсендә әсәрнең асыл мәгънәсен аңлау;
– эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;
– билгеләгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белү;
укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү. --әйтелгән фикерне текстан өзекләр яки җөмләләр белән дәлилләү;
- төрле фикерләрнең төрле нигезләре булырга мөмкин икәнлеген аңлау;
- башкарылган эшләрнең һәм алынган нәтиҗә буенча үзбәя һәм башкалар хезмәтенә бәя кую;

**Коммуникатив нәтиҗәләр:**

– Әңгәмәдәшеңне тыңлый һәм диалог кора белү; сөйләм барышында төрле фикерләр булырга мөмкинлеген аңлау әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзи белү;
– аралашучанлык, хисслелек, эмпатия хисләре формалашу;
– парларда һәм күмәк эшли белү.
- аралашу һәм хезмәттәшлек итү;
- бергә утырган иптәшең белән бергә эшләү: кечкенә төркемнәрдә эшләү: үзара эшләрне һәм
рольләрне бүлешү, үзеңә бирелгән эшне башкару һәм аны гомуми эшнең бер өлеше итү;
- төрле фикерләр һәм карашлар арасында аермалыкларны аңлау, шул фикерләрнең берсенә кушылу һәм ни өчен икәнлегенең сәбәбен дәлилләү;
– текстан геройлар әйткән фикерләрнең дөреслеген дәлилли торган фикерләрне табу;

– тексттан геройлар әйткән фикерләрнең дөреслеген дәлилли торган фикерләрне табу;

**4 нче сыйныф укучылары өйрәнү мөмкинлеге алалар:**

-- дөнья халыклары, рус халык , татар халык әкиятләрендә бирелгән дөньяны мифологик кабул итү үзенчәлекләрен күзәтү;

-- шигырьнең шагыйрь сайлаган шигъри формада бирелүенең уңышлы булуын (классик һәм бүгенге көн шигърияте әсәрләренә нигезләнеп) дәлилләү;

-- әдәби әсәрнең язылу тарихында язучы (шагыйрь, рәссам) биографиясенең әһәмиятле урын алып торуын аңлау;

-- сәнгатьнең төрле төрләренә караган (әдәби, музыка, рәсем сәнгате) әсәрләрнең эчтәлек буенча гына түгел, ә бәлки авторларның тормышны кабул итүе буенча охшашлыгына да бәйле булуын аңлау;

-- шигъри һәм чәчмә әсәрләрне сәнгатьле итеп кычкырып уку;

-- дәреслектәге иллюстрацияләрне карау, музыкаль әсәрләрне тыңлау, аларны әдәби һәм сынлы сәнгать әсәрләренең эчтәлеге белән чагыштыру, аларга салынган фикер, хисләр һәм кичерешләрне аңлау;

-- әдәби, музыкаль, сынлы сәнгать әсәрләрен анализлау барышында, телдән һәм язмача (фикерләрне язу яки кыска сочинениеләр формасында) үзеңнең шәхси киччерешләреңһәм күзәтүләрең белән уртаклашу;

-- әдәби укуның кешедә гомуми культура булдыруда һәм дөньяны танып-белүдә укуның әһәмиятен аңлау;

-- әдәби әсәрләрне укып өйрәнү һәм аларга бәя бирү барышында үзеңдәге рухи-әхлакый сыйфатларны уңай якка үзгәртергә теләк уяну һәм үзеңнең эш-гамәлләреңә бәя бирү;

-- китапханәдән китаплар һәм вакытлы матбугат сайлаганда, тышлыкка карап сайлау, шулай ук китапларның “Эчтәлек” битен файдалану;

-- дәрестә текст белән эшләү өчен өстәмә хрестоматиядән, өйдән алып килгән китаплардан файдалана белү;

-- үзеңнең шәхси кичерешләрен һәм күзәтүләрең белән телдән уртаклаша белү;

-- хайваннар турындагы әкиятләрдәге вакыйгаларның вакыт аралыгында үсеше;

-- әкиятләрне әдәби әсәрләр белән чагыштыру;

- төрле җыентыклар (монография, жанр буенча һәм тематик җыентыклар) ясау алгоритмын белү;

**Предмет нәтиҗәләре:**

**4 эшчәнлек төре һәр дәрестә оештырыла.**

**Уку**

-- шигъри һәм чәчмә әсәрләрне сәнгатьле итеп уку;

-- уку тизлеген арттыра барып, сүзләрне тулы әйтеп кычкырып уку;

-- текст белән беренчел танышканда, өлешләп укыганда һәм кабатлап укыганда эчтән уку;

-- укыган текстка карата кыскача монологик фикерләмә укытучы соравына кыска һәм тулы җавап бирү;

-- әңгәмәдәшеңне (укытучыны, сыйныфташыңны) тыңлау: әйтелгән фикерне кабатламау, башкалар әйткән фикерне тулыландыру;

-- татар әдәбиятының 2-3 классигының исемен әйтү, әсәрләрнең исемнәрен атау һәм кыскача эчтәлекләрен сөйләү;

-- яраткан язучың турында әйтә белү һәм аның әсәрләрен атау, аларның эчтәлеге турында кыскача гына әйтә белү;

- дәрестә өйрәнгән төп әсәрләрнең эчтәлеген белү. Аларның авторын һәм исемен белү;

-- әсәрнең төп темасын һәм фикерен (укытучы ярдәме белән) аерып чыгару;

-- сүзләрнең мәгънәсен ачыклау өчен аңлатмалы сүзлекбелән эшли белү;
-- Кычкырып укыган кечкенә күләмле әсәрләрнең эчтәлеген ишетеп аңлау, алардагы логик өлешләрне аерып әйтә белү;
-- әдәби әсәрләрнең өлешләрен рольләргә бүлеп һәм чылбырлап уку; сәхнәләштерү,
-- текстның билгеләгән өлешләрен аерып алып эчтән уку һәм укыган өлешләрнең төп фикерен аңлау;
- сайлап алып төрле авторларның 3-4 әсәрен яттан сөйләү;
- ике яки өч балалар журналының исеменәйтү һәм аларның эчтәлегенә (рубрикаларына) күзтү ясау;
- әдәби әсәрләрнең геройларына характеристика бирү, бер яки берничә әсәрнең геройларын чагыштыру. Авторның геройга мөнәсәбәтен ачыклау;
- сайлап алып шигъри әсәрләрне яки алардан өзекләрне сөйләү; яттан сөйләүгә сыйныфташлары тарафыннан әйтелгән тәнкыйди фикерләрне дорес кабул итү;
- әдәби әсәр турында үзеңнең фикереңне нигезли белү һәм үз фикереңне әсәрдән өзекләр яки аерым җөмләләр белән дәлилләү;
- бер әсәргә яки җыентыкка аннотация төзү;
- төрле юнәлештәге биремнәрне чишү максатыннан (тәкъдим ителгән исемлек буенча, билгеле бер темага чыгыш әзерләү өчен һ.б.) китапханәдән кирәкле китапларны мөстәкыйль сайлау;

**Сөйләү**

– программа кысаларында сөйләм бурычына туры килгән лексик-грамматик материалны кулланып, әңгәмәдәшең белән контактка керү: сөйли, сорый белү; сөйләмне башлый, дәвам итә, төгәлли белү;
– телдән монологик сөйләм (тасвирлау, хикәяләү, фикер йөртү) күнекмәләренә ия булу; орфоэпик нормаларны үтәү;
– өйрәнгән әсәрләрнең темасын һәм төп фикерен билгеләү, текстны берничә мәгънәви кисәккә бүлү; текстның планын төзү һәм аны эчтәлекне сөйләгәндә куллана белү; текстны кыскача һәм тулы итеп сөйләү;
– өйрәнгән әсәрләрнең авторларын – әдипләрнең һәм шагыйрьләрнең исемнәрен әйтә белү,аларның берничә әсәрен атау, сыйныфта укыган әсәрләрнең кыскача эчтәлеген сөйләү,
– үзеңә ошаган әдәби герой турында сөйләү;
-- дәреслектәге иллюстрацияләрне карау, аларны текст эчтәлеге һәм текстта бирелгән төп фикер (хисләр, кичерешләр) белән тәңгәлләштерү, алар буенча җөмләләр төзү, фикереңне белдерү;
– укыганның эчтәлеген сөйләү, эчтәлеккә карата фикереңне әйтә белү;
- үеңә ошаган әдәби герой турында сөйләү;
– текстны үзгәртеп, аналогик текстлар төзеп сөйләү;
– көндәлек аралашу ситуацияләренә бәйле сөйләм этикеты үрнәкләрен гамәли үзләштерү (сәламләү, саубуллашу, гафу үтенү, рәхмәт әйтү, үтенеч белдерү); өйрәнгән тема буенча диалогик сөйләмгә чыгу, гади диалогларда катнашу;
– сөйләм этикеты үрнәкләрен кулланып, гади диалогларда катнашу;
– предметны, персонажны яки рәсемне тасвирлау.
- үзеңнең шәхси кичерешләрен һәм күзәтүләрең белән телдән уртаклаша белү;
- төрле авторларның 3-4 әсәрен (сайлап алып) яттан сөйләү;

**Тыңлап аңлау**

-- укыганның эчтәлеген аңлау, тиешле интонацияне, уку темпын һәм тиешле тукталышларны текст эчтәлегеннән чыгып аңлап сайлый белү,
-- иллюстрацияләрне карау, аларны текст эчтәлеге һәм текстта бирелгән төп фикер (хисләр, кичерешләр) белән тәңгәлләштерү
-- укытучы укыган текстны ишетеп аңлау күнекмәләрен үстерү;
-- укыган әсәр эчтәлегенә телдән үзенең фикерен белдерү;
-- зур булмаган текстны сөйли белү;
-- дәрестә текст белән эшләү өчен өстәмә хрестоматиядән, өйдән алып килгән китаплардан файдалану;
-- әсәр эчтәлеге буенча сораулар төзү һәм бирелгән сорауларга җавап бирү;
-- шигъри әсәрләрне чәчмә әсәрләрдән аера белү;
-- фольклор әсәрләренең кече жанрларын аеру: табышмак, санамыш, тизәйткеч, атамыш;
-- тексттагы тел-сурәтләү чараларын таба белү (кабатлау, сүзләрнең иркәләү-назлау формалары, өндәү һәм сорау билгеләре, рифмалар)
-- шигъри әсәрләрнең үзенчәлекләрен белү (ритм, рифма һ.б), төр үзенчәлекләрен аеру (эпик, лирик, драма), халык авыз иҗаты әсәрләренең төрләрен белү (бишек җырлары, санамышлар, әкиятләр, мәкальләр һ.б.)
--рольләргә бүлеп уку, сәхнәләштерү, телдән тасвирлау, репродукцияләр белән эшләү
– аралашу барышында укытучының һәм сыйныфташларның сөйләмен ишетеп аңлау, вербаль яки вербаль булмаган рәвештә җавап кайтару;
– тыңлана торган тексттагы мәгълүматны аңлау, аның эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү.

**Язу**

– тексттан сүзләрне, сүзтезмәләрне, гади җөмләләрне күчереп язу;
– үрнәк буенча бәйрәмгә чакыру язу;
– үрнәк буенча дустыңа хат язу;
– сөйләм бурычын аңлап, кыскача үз фикереңне язмача белдерү.
– текстның эчтәлеге буенча сорауларга язмача җавап бирү;
– терәк сүзләр ярдәмендә кечкенә хикәя төзеп язу;

## Укыту предметының эчтәлеге

### 1 нче сыйныф

| № | Бүлек исеме | Укыту программасы бүлегенең төп эчтәлеге |
|---|---|---|
| 1 | Әйдәгез танышабыз. | Сүзлек запасын барлау. Дәреслек белән эшләү барышында иллюстрацияләрне карау, аларны текст эчтәлеге һәм текстта бирелгән төп фикер белән тәңгәлләштерү. Г.Тукайның “Шүрәле” әкиятен искә төшерү.Шүрәлене уңай әдәби герой һәм дус буларак кабул итү. |
| 2 | Мәктәптә. Белем бәйрәме. Белемле кеше – көчле кеше | Уку-язу әсбапларының исемнәрен белү, сүзлек запсын баету. “Мәктәп” темасына караган тел шомарткычлар белән танышу. Фольклор әсәрләренең кече жанрларын аеру. Белгән сүзләрне кулланып җавап бирә белү. Спорт бәйрәме турында сөйләшү. Габдулла Тукай “Эш беткәч уйнарга ярый” шигыре белән рәсемнәр һәм мультфильм аша танышу. Иллюстрацияләр белән эшләү |

| | | |
|---|---|---|
| 3 | Күз. Күзге муллык | Яшелчәләр һәм җиләк-җимешләрнең исемнәрен атау, сүзлек запасын баету, аларга хас билгеләрне кулланып сүзтезмәләр һәм җыйнак җөмләләр төзү. “Шалкан” әкиятен сөйләү, рольләргә бүлеп әкиятне уйнау. |
| 4 | Кышны яратабыз. Яңа ел | Әминә Бикчәнтәева “Салкын саф һава”, Гөлшат Зәйнәшева “Кыш”, Афзал Нигъматуллин “Беренче кар” шигырьләрен өйрәнү. Яттан истә калдырырга тырышу. “Бәйрәмгә барабыз” хикәясе. Иҗекләп һәм сүзләр белән, өзлексез салмак тавыш һәм билгеле бер темп белән кычкырып уку. |
| 5 | Минем гаиләм. | Гөлшат Зәйнашева “Әбиемне яратам” шигыре. “Безнең гаилә” хикәясе. Иҗекләп һәм сүзләр белән, өзлексез салмак тавыш һәм билгеле бер темп белән кычкырып уку<br>“Бу бармак – бабай...”(санамыш).<br>Санамышлар турында төшенчә бирү. Белгән санамышларын барлау. Татар телендә бер-ике гади санамышны истә калдыру. Зәкия Туфайлова “Әни сүзе” шигыре. Укытучы укыганны тыңлау һәм аңлау. Текстны истә калдыру һәм яттан сөйли белү. |
| 6 | Тылсымлы сүзләр | Әдәпле сүзләр белән танышу, кыска диалогик сөйләмгә чыгу. Бергә аралашу һәм хезмәттәшлек итә белү. Башкаларны тыңлый белү. Ләбиб Лерон “Хәерле иртә!”шигыре. Шәүкәт Галиев “Тыныч йокы!” шигыре. Җари Рәхмт “Рәхмәт” шигыре. |
| 7 | Минем туган көнем | Зиннур Хөснияр “Курчак алдылар миңа” шигыре. Музахит “Тутый кош”. Гүзәл Исхакова “Куанычым”<br>Белгән сүзләрне барлау, сүзлек запасын баету. Текст белән эшләү. Иҗекләп һәм сүзләр белән, өзлексез салмак тавыш һәм билгеле бер темп белән кычкырып уку. |
| 8 | Яз. Яз килә | Яз билгеләрен әйтә белү. Сүзлек запасын барлау һәм баету. Белгән сүзләрне кулланып иллюстрацияләр буенча сөйләм төзү. Бер үк сораугa төрлечә җавап бирү мөмкин икәнлеген аңлау. Әхмәт Ерикәй “Тышта яз".Нури Арслан “Яз” шигыре. Язгы авазлар. Г.Тукайдан. |
| 9 | Безнең дусларыбыз (Йорт хайваннары һәм кошлары, кыргый хайваннар) | Кыргый хайваннар һәм йорт хайваннарының исемнәрен белү, яңа сүзләр өйрәнү. Алаврга хас билгеләрне атап сүзтезмәләр төзү. Г.Тукайның “Гали белән Кәҗә” шигырен өйрәнү. Геройларга бәяләмә бирү. Рус халык әкияте”Теремкәй”. |
| 10 | Җәй. Матур җәй | Җәй билгеләрен әйтә белү. Роберт Миңнуллин “Болыт”шигыре. Бари Рәхмәт “Су” шигыре.Гамир Насрый “Зәңгәр күл”. “Җиләк җыям- как коям” уенын өйрәнү. Сабантуй бәйрәме турында сөйләшү. |
| 11 | Халык авыз иҗаты | Тизәйткечләр, тел шомарткычлар.<br>(“Кара карга карга куна...”, “Дуслар кая барасыз?”). Табышмаклар, Санамышлар. Фольклор әсәрләренең кече жанрлары турында төшенчә бирү, аларны аеру, аларның әһәмиятен билгеләү. |
| | | **2 нче сыйныф** |
| 1 | Мәктәптә. Белем бәйрәме. Белемле кеше – көчле кеше | Ринат Маннан “Исәнме, мәктәп!” шигыре. Бари Рәхмәт “Мәктәпкә”, Михаил Пляцковский “Өйрәтәләр мәктәпләрдә”, Барлас Камал “Иң күңелле көн”, Рус халык әкияте “Күмәч”. Әкиятләрне хикәяләрдән аеру, рольләргә бүлеп уку, уку барышында геройларны төрле интонацияләр аша бирү. Тиешле интонацияне, уку темпын, тукталышларны текст эчтәлегеннән чыгып аңлап сайлый белү. |
| 2 | Көз. Көзге муллык | Көз билгеләрен атый белү. Айгөл Әхмәтвлиева “Көзге муллык”, Әхмәт Ерикәй “Уңыш”, Шәүкәт Галиев “Витамин эзли”, Ринат Маннан “Помидор егете”, Всимә Хәйруллина “Толымлы суган”, Фәнис Яруллин “Көзгә табын”, Алмаз Нигъматуллин “Алмагач һәм алма”, Ләбиб Лерон “Яфрак бәйрәме” шигыре. Г.Гәрәева “Көз һәм балалар җыры” шигыре. Әсәрнең төп темасын һәм фикерен (укытучы ярдәме белән) аерып чыгару, шигъри әсәргә хас үзенчәлекләрне атау һәм аерып чыгару, шигырьне җыр итеп башкарырга мөмкин икәнлеген әйтү һәм җырлау. |

| | | |
|---|---|---|
| | | Рус халык әкияте “Шалкан”. |
| 3 | Кыш. Кышкы уеннар. Яңа ел | Җәүдәт Дәрзаманов “Кыш”, Зәкия Туфайлова “Кыш килде”, Гәлимҗан Латыйп “Кыш шатлыклары”, Музахит “Яңа ел кайдан килә?”, Нәҗибә Сафина “Кышкы җыр”, Гасыйм Лотфи “Кар бөртекләре”. Уку тизлеген арттыра барып, сүзләрне тулы әйтеп кычкырып уку. Галимҗан Латыйп “Яңа ел җыры” (Яңа ел турында җыр). Әсәрнең төп темасын һәм фикерен (укытучы ярдәме белән) аерып чыгару, шигъри әсәргә хас үзенчәлекләрне атау һәм аерып чыгару, шигырьне җыр итеп башкарырга мөмкин икәнлеген әйтү һәм җырлау. |
| 4 | Безнең гаилә | РафисКорбан “Атна көннәре”, Зәкия Туфайлова “Шофер булам”, Рөстәм Мингалим “Крокодил күрдем”, Айгөл Әхмәтгалиева “Безнең өйдә”Роберт Миңнуллин “Уятыйм әле” тексты. Шәйхи Маннур “Яратам” шигыре. Айдар бездә кунакта” тексты. Шигъри текстны чәчмә әсәрләрдән аера торган билгеләрне табу. Әңгәмәдәшеңне тыңлау, сорауларга җавап бирү. Сүзлек белән эшләү. |
| 5 | Минем туган илем | “Татарстан – минем республикам”” тексты. Равил Фәйзуллин “Җир өстендәниләр бар?, Резедә Вәлиева “Иң матур җир”, Әхмәт Рәшитов “Кояшлы ил – безнең ил”, Энҗе Мөминова “Туган ил”, “Мин авылда яшим” тексты.<br>Укытучы укыган текстны ишетеп аңлау күнекмәләрен үстерү. М.Җәлилнең биографиясе.<br>“Әтәч” шигыре. Яраткан язучың турында әйтә белү. Әсәрнең төп темасын һәм фикерен аерып чыгару. Сүзлек белән эшләү. Шигъри текстка хас билгеләрне атау. |
| 6 | Яз.Яз килә. | Равил Фәйзуллин “Кар кызы кая киткән?”, минә Бикчәнтәева “Апрель ае”, Марс Шабаев “Ташу”, Роберт Миңнуллин “Яз керде өебезгә”, Йолдыз Шарапова “Тузганак”, Идрис Туктар “Витаминнар”, Хакимҗан Халиков “Рәхмт сезгә, ветераннар!” “Әниләр бәйрәме” темасына сөйләшү. Җырлыйм әнием турында.<br>Әниләр турында җырлар Сүзлек белән эшли белү. Телдән момнологик һәм диалогик сөйләм төзү. Аралашу, хезмәттәшлек итү. Зәкәрия Әхмәров “Агачлар да авырый”.<br>Чәчмә текстны шигъри текстан аера белү, эчтәлекне ишетеп аңлау. |
| 7 | Кошлар – канатлы дусларыбыз. | Шәйхи Маннур “Исәнмесез, кошкайлар!” шигыре.Гасим Лотфи “Балалар ярдәм итә”, Фәнис Яруллин “Чыпчык”, Гасим Латыйп “Тукран”, Музахит “Күгәрченнәр гөрлиләр”, Муса Җәлил “Күке”, Афзал Нигъматуллин “Песи Һәм чыпчык”, Гәрәфи Хәсәнов “Кошларга ярдәм” шигыре.<br>Укытучы укыган текстны ишетеп аңлау күнекмәләрен үстерү. Шигъри текстны укыганны тыңлау, ишетеп аңлау, сүзлек белән эшләү. Текст эчтәлеген караган иллюстрация белән чагыштыру. |
| 8 | Җәй. Матур җәй | Җәй билгеләре. “Җәй җитте” тексты. Гөлшат Зәйнәшева “Без – табигать дуслары”,“Сабантуй”, Ильдар Юзеев “Гөл нигә шиңгән?”, Әминә Бикчәнтәева “Колын”, Ринат Мәннан “Яратмыйм”. Текст белән беренчел танышканда, өлешләп укыганда һәм кабатлап укыганда эчтән уку. Текст эчтәлеген күзәтүләрең белән бәйләү. Диалогик һәм монологик сөйләмгә чыгу. Габдулла Тукай “Бала белән Күбәләк” шигыре. |
| 9 | Халык авыз иҗаты | Табышмаклар. Санамышлар.<br>Халык авыз иҗаты әсәрләре, аларның кече жанр төрләре турында белү. Табышмакларны һәм санамышларны аера белү. Аларның әһәмиятен әйтү, истә калдыру. Табышмаклар уйлау. |
| | | **3 нче сыйныф** |
| 1 | Мин җәйне ничек үткәрдем | Кереш дәрес. “Сау бул, җәй! Исәнме, мәктәп!”<br>“Беренче сентябрь” тексты.Дамир Гарифуллин “Август”, Энҗе Авзалова “Көзге моңсулык”, Г.Тукай “Көз”, Вакыйф Нуриев “Китап”, Газинур Морат “Туган тел”, Каюм Насыйри “Акыллы һәм яхшы холыклы”. М.Галләмова “Чын иптәш” тексты. Ш.Галиев “Онытылган...” шигыре. Өйрәнгән әсәрләрнең авторларын – әдипләрнең һәм шагыйрьләрнең исемнәрен әйтә белү. |
| 2 | Кызык кызлар һәм малайлар | “Китапханәдә” тексты. Г.Зәйнәшева “Бер атнада ничә көн?” шигыре. “Ашханәдә” тексты. Б.Рәхмәт “Бармаклар җитми” шигыре.Ә. Рәшитов “Футболчы, имеш”, Ринат Маннан “Җиләк җыйганда”, Роберт Миңнуллин “ Малайлар сөйләшә”. Шигъри һәм чәчмә әсәрләрне чагыштыра белү, аларның уртак якларын табу, тема- идеясен билгеләү. Үз мөнәсәбәтеңне белдерү. |

| | | |
|---|---|---|
| 3 | Кыш. Кышкы уеннар. Яңа ел | Кыш билгеләре. Р.Миңнуллин “Чыршы әйләнәсендә” шигыре “Чыршы” бәйрәме” тексты. Әминә Бикчәнтәева “Салкын саф һава” шигыре. “Тауда”,Фатих өсни “Беренче кар”, Виталий Бианки”Куян, Көртлек, Аю һәм Кыш бабай” , Г.Тукай “Җир йокысы”, Абдулла Әхмәт “Кышкы матурлык”шигырьләре. “Каникулда” тексты. Үзеңә ошаган әдәби герой турында сөйләү. Геройга карта авторлык мөнәсәбәтен ачыклау. |
| 4 | Минем туганнарым | Г.Тукайның биографиясе. “Безнең гаилә” шигыре. Р.Миңнуллин “Торам менә елмаеп”, Резедә Вәлиева “Туган көндә”, Әнәс Хасанов “Сез ни әйтерсез икән?”, Ф.Яруллин “Кояштагы тап”, Ш.Галиев “Җиргә язны кем китерә”, Дәрдемәнд “ Кояш нурлары”.<br>Өйрәнгән әсәрнең авторын әйтә белү,аларның берничә әсәрен атау, сыйныфта укыган әсәрләрнең кыскача эчтәлеген сөйләү. И.Әхтәмов “Ана рәхмәте” хикәясе. “Акыллы малай” тексты. Ә.Бикчәнтәева “Дәү әнием”, Х.Халиков “Без ничәү?” |
| 5 | Туган җирнең кадерен бел | Гомәр Бәширов “Нинди ул Татарстан?”, Равил Фәйзуллин “Безнең КамАЗ”, Роберт Миңнуллин “Авыл малае белән шәһәр малае сөйләшкәне”Рәшит Башар”Шәһәр төзим”, Энже Авзалова “Бу гүзәллек яшәрме?”, Гариф Галиев “Туган ил кайдан башлана?”<br>Ш.Галиев “Җирдә миңа ни кирәк?”, Әнәс Кари “Гөл янында”, Разил Вәлиев “Зоопаркта”, Хәкимҗан Халиков “Ятим тургай”.<br>“Татарстан – зур республика” тексты<br>Уку тизлеген арттыра барып, сүзләрне тулы әйтеп кычкырып уку. Рольләргә бүлеп уку. Эчтәлеккә, геройларга карата карата үз фикереңне, мөнәсәбәтеңне белдерү. |
| 6 | Яз.Яз килә. | Яз килә. Яз билгеләре. “Төсләр” әкияте. 8 нче Март - әниләр бәйрәме! “ тексты. Проект эше “Бәйрәм белән, әнием!” Проект эше “Бәйрәм белән, әнием!” |
| 7 | Кечкенә дусларыбыз | М.Галләмова “Дуслар” хикәясе. Гасыйм Лотфи “Батыркай”, Лиана Амирханова “Нәни дусларым”, Рафис Корбан “Пескәем”, Гомәр Бәширов “Песинең туган көне”, Нәҗип Мадьяров “Тукран”.<br>“Кем нәрсә ярата?” әкияте.<br>Әкиятнең хикәядән (әдәби әсәрдән) аермасын билгеләү, аңа хас булган төп билгеләрне аеру. Текстны чылбырлап, кычкырып, рольләргә бүлеп уку. |
| 8 | Сәламәт тәндә - сәламәт акыл | М.Җәлил “Сәгать” шигыре. И.Туктар “Авыраяк” хикәясе.<br>Х.Халиков “Витаминлы аш” хикәясе. Йолдыз Шарапова “Татарстан – спорт иле”, Гәлимҗан Гильманов “Хәрәкәттә – бәрәкәт”, Сания Әхмәтҗанова “Үрнәк алыйк”, Әхмәт Ерикәй “Чисталык сөябез”, Мәрзия Фәйзуллина “Җәй җитте” Р.Миңнуллинның биографиясе.<br>“К”лар тулган бакчага” шигыре.<br>Өйрәнгән әсәрләрнең авторларын – әдипләрнең һәм шагыйрьләрнең исемнәрен әйтә белү. Шигырь текстын чәчмә әсәр текстыннан аера белү. |
| 9 | Кабатлау. Шигырь төзелеше. | Шигырь төзелеше. Ритм, рифм турында белгәннәрен мисаллар нигезендә үстерү. Г.Тукай, Б.Рәхмәтнең шигырьләре (“Елның дүрт фасылы”) буенча шигырь төзелешенә бәя бирү. “Җиләк кайда күп?” шигыре. “Сабантуй – зур бәйрәм”. Әкият- табышмак “Бүре, кәҗә, кәбестә”. |
| | | **4 нче сыйныф** |
| 1 | Мәктәптә. Белем бәйрәме. Белемле кеше – көчле кеше | С.Маршак “Һәр атнада җиде көн” шигыре. Х.Гарданов “К “ ны дөрес әйтегез”, Р.Миңнуллин “Үсми калган хәреф” шигырьләре. “Эш урыны” тексты. Әсәрдә сурәтләнгән геройга бәяләмә бирү, күзәтүләреӊ һәм үзеӊ белән бәйләү.Сүзлек белән эшләү.Ш.Маннур “Хуш килдегез!”, Р.Вәлиева “Рәсем дәресендә”, Васимә Хәйруллина “ Балачак утравы”, Йолдыз”Күңелле тәнәфес”, Мөхәммәт Садри “Минем әби” шигырьләре. |
| 2 | Кыш. Кышкы уеннар. Яңа ел | Ә.Ерикәй “Беренче кар” шигыре. Шигъри текстка хас булган билгеләрне атау, ритм-рифманы билгеләү. Г.Бакир “Кышкы уен” хикәясе. Б.Рәхмәт “Яңа ел килгәч”, “Кыш бабай елкада” шигырьләре.Рәйсә Ишмуратова “Яңа чана”. |
| 3 | Татарстан-минем туган җирем | Җ.Тәрҗеманов “Табигать китабы” , Г.Гәрәева “Көз һәм балалар җыры” шигырьләре. В.Монасыйпов “Шифалы табиблар” хикәясе. “Дару үләннәре” тексты. |

| | | |
|---|---|---|
| | | Б.Рәхмәт “Кошлар киткәндә” шигыре. “Очты, очты...” уены. Шигъри текстка хас булган билгеләрне табу, тел-сурәтләү чараларын билгеләү. Шигъри текст белән уен ны бәйләү. З.Туфайлова “Туган ил” шигыре, Ф.Яруллин “Татарстан байрагы”, М.Җәлил “Җилләр”, Әхмәт Синагул “Татарстан җирләре”, Х.Туфан “И нурлы Казан”. Татарстан символлары. Казан турында легендалар. Лена шакиҗан “Сөембикә манарасы”, Бари Рәхмәт “Зәңгәр күл” шигырьләре. |
| 4 | Китап – белем чишмәсе | Х.Халиков “Яңа дус таптым”, Хәсән Шабанов “ Кадерлә син китапны”, З.Туфайлова “Безнең китапханәдә”, Ж.Дәрзаман “Якын дус”, Р.Фәхретдин “Уку әдәпләре. “Алсу мәктәптән кәефсез кайтты” тексты. Г.Тукай”Эш беткәч уйнарга ярый” шигыре. Шигъри текстны хикәя текстыннан аера белү, эчтәлекне ишетеп аңлау. Бирелгән шигъри текстның мультфильм формасында да була алуын күзәтү. Рольләргә бүлеп уку, геройларны төрле интонация төсмерләре аша белдерү. |
| 5 | Дуслык | А.Алишның биографиясе , “Куян кызы” әкияте. “Елга буенда хикәясе. “Минем дустым” хикәясе. Г.Бәширов “Сылтау” хикәясе. Б. Рәхмәт “Минем дуслар” шигыре.Р.Вәлиева “Дуслык” “Кыңгырау чәчәк”, В.Хәйруллина “Әйдә, танышабыз”, М.Галлямова “Чын иптәш”, Б.Рәхмәт “Әби белән бабушка”, Л.Толстой “Бүре белән тиен”. |
| 6 | Яз.Яз килә. | Карга боткасы (Грачиная каша)Нәүрүз бәйрәме. Укучыларның белгәннәренә таянып, татар халкының йолалары турында белемнәрен үстерү, Карга боткасы турында белешмә бирү. Л.Толстой “Әби белән оныгы” хикәясе. Мәхмүт Газизов “Рәхмәт” шигыре.С.Сөләйманова “Әниләр бәйрәме”, Р.Вәлиева “Туган көндә”, Г.Бәширов “ Табигатьтә яз”, Б.Рәхмәт “ Сыерчыктан телеграмма”, Р.Миңнуллин “Әйлән-бәйлән”, Р.Вәлиева “Җиңү көненде”. Мәдинә Маликова “Һәйкәл янында”, Вәсимә Хәйруллина “Билгесез солдат” шигырьләре. В.Осеева “Дүрт кыз” хикәясе. |
| 7 | Яхшылыкта – яктылык | Г.Лотфи “Песнәк белән Әнисә” хикәясе. “Чирик” хикәясе. И.Туктар “Алма” хикәясе. Д.Аппакова “Шыгырдавыклы башмаклар” хикәясе. Р.Мингалим “Дөньяда бер эт бар иде”, Г.Тукай “Кызыклы шәкерт” шигырьләре. Г.Мөхәммәтшин “Ак песи” хикәясе. Р.Батулланың биографиясе. “Чикыл белән Мырый” әкияте.Сәрвәр Әдһәмова “Дуслар”, .Баян “Эт янында тиеннәр” |
| 8 | Җәй. Матур җәй | Ш.Галиев “Җәйге болында” шигыре.” Р.Корбан “Җиләктә” шигырьләре”.Ә.Бикчәнтәева “Каен җиләге”, Р.Миңнуллин “Сабантуй бүген бездә”, “Сабантуй” хикәясе. |
| 9 | Халык авыз иҗаты | Әкиятләр. “Шүрәле” әкияте. “Ташбака белән Куян” ,“Яшел энәле керпе” әкиятләре. Проект эше “Без әкият яратабыз”. Әкиятләрнең геройларына, аларның эш - гамәлләренә бәя бирү. Халыкларның әкиятләрдә бирелгән дөньяны мифологик кабул итүен күрү.Татар халык әкияте “Куркак юлдаш”. |
| 10 | Кабатлау. Шигырь төзелеше | Шигырь төзелеше турында белешмә бирү. Ритм, рифма. Шигырьдәге каршылыкны таба белү. Үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау. |

**Сөйләм һәм уку эшчәнлегенең төрләре:** сөйләмне ишетеп аңлау, текстны кабул итү, эчтәлек буенча сораулар га җавап бирү, эчтәлек буенча ишетеп сораулар төзү, вакыйгаларның эзлеклеген төзү;
**Ишетеп аңлау (аудирование):** яңгыраган сөйләмне ишетеп аңлау: укытучы һәм сыйныфташлары кычкырып укыганны, иптәшләре сөйләгәнне, үзенә бирелгән сорауларны кабул итү; ишеткән сөйләмнең эчтәлеген аңлау, эчтәлек буенча сораулар төзү һәм бирелгән сорауларга җавп бирү;
**Кычкырып уку:** иҗекләп укудан сүзләп укуга күчү һәм уку тизлеген үстерә бару; кычкырып уку, чылбырлап уку, рольләргә бүлеп уку теләге формалаштыру; сәнгатьле уку үзенчәлекләрен үзләштерү;
**Эчтән уку:** зур булмаган текстларны мөстәкыйль укый белү; сайлап уку барышында өйрәнелә торган тексттан һәм сүзлекләрдән кирәкле мәгълүматны таба белү.
**Сөйләм:**монологик сөйләмнең төрләрен үзләштерү; эчтәлекне тулы һәм кыскартып сөйли белү; диалогик аралашуның үзенчәлекләрен үзләштерү; иптәшеннен сөйләмен тыңлый һәм аның сөйләменә карата үз фикереннe белдерү;
**Язу:** эш дәфтәрендә язмача күнегүләр башкару; күзәтүләрдән һәм тормыш тәҗрибәсеннән чыгып кыска сочинениеләр язу; рәсемнәргә карап мини-сочинениеләр язу; хәбәрләрнең һәм хатларның төрле төрләрен язу;

**Әдәби әсәр тексты белән эшләү:** сорау һәм биремнәргә нигезләнеп текстны аңлау һәм фикер алышу; лирик әсәрләрдәге эчке кичерешләрне аңлау; геройларның капма-каршы фикерен һәм авторның нәтиҗәсен таба белү; төрле төр әсәрләрдәге интонация аңлау һәм белдерү (бишек җыры, сөйләк, гимн һ.б.); тестның сәнгатьлелек ягыннан төзелешен әйтә белү; сөйләменә һәм эш-гамәлләренә карап, геройның характерын билгели алу, геройның үсешен күзәтү; төрле геройларның эш-гамәленә бәя бирү; чәчмә әсәрләрдә авторның фикеренә һәм лирик әсәрләрдә кичерешләренә бәя бирү; сәнгатьлелек чараларын табу;

**Уку текстлары һәм фәнни-популяр текстлар белән эш:** текст эчтәлеген аңлау; текст эчендә өлешләрне, әһәмиятле сүзләрне табу; эчтәлекне сөйләү өчен план төзү.

**Сыйныфтан тыш уку:** укучыларны әдәби китапларны мөстәкыйль укый алу өчен әзерләү;балаларда әдәби китаплар укуга теләк булдыру, китапны кешелек мәдәниятенең бер өлеше буларак кабул итәргә өйрәтү;

**Халык авыз иҗаты:** "халык авыз иҗаты" төшенчәсен аңлау, кече фольклор әсәрләре (санамышлар, табышмаклар, тизәйткечләр, мәкальләр, бишек җырлары; тылсымлы, көнкүреш, хайваннар турындагы әкиятләр) жанрлары турында белемнәрен системалаштыру; фольклор әсәрләре һәм аларның төрләре турында белү; мәсәлләр турында белү; хикәя жанры, әдби әкиятләр, автор шигърияте; лирик әсрләрнең үзенчәлекләре (ритм, рифма); "тема", "төп фикер" төшенчәләрен белү; герой кичерешләрен аңлату; сюжет төшенчәсен аңлау; геройга бәяләмә бирә белү; сәнгатьлелек чараларын билгеләи һәм таба белү;

**Төрле төрдәге һәм жанрдагы текстлар белән эшләү:** әсәрнең халык авыз иҗатына караганын яки автор әсәре икәнлеген аера белү;текстларның жанр үзенчәлекләрен аңлау; текстларны аера белү (әдәби, фәнни-популяр);чәчмә (проза) һәм шигъри ( поэзия) әсәрләрнең үзенчәлекләрен аңлау;

**Сәнгатьнең төрле төрләренә караган әсәрләр белән эшләү**: ( әдәбият, рәсем сәнгате, гамәли сәнгать,сынлы сәнгать, музыка һ.б.) Алар арасында уртаклык һәм специфик аермалыкларны табу;

**Иҗади эшчәнлек элементлары:**әдәби әсәрләрне (яки өзекләрне) рольләргә бүлеп яки чылбырлап уку; проза һәм поэзия әсәрләрен сәнгатьле итеп укый белү;тиешле интонацияне дөрес сайлап һәм тиешле урында тукталышлар ясап укый белү; дәреслектәге иллюстрацияләр белән эшли белү һәм аларны әдәби текст белән чагыштыру; телдән һәм язмача үзеңнең шәхси тәэсирләрең белән уртаклаша алу ( кечкенә сочинение һәм телдән фикерләмә);

**Балаларның уку даирәсе:** халык авыз иҗаты әсәрләре; фольклорның кече жанрлары (бишек җырлары, санамышлар, тизәйткечләр, табышмаклар, каргыш-теләкләр); халык әкиятләренең барлык төрләре, мәкальләр һәм әйтемнәр; автор әсәрләре, мәсәлләре; безнең илнең 19 – 20 нче гасыр әдәбияты классикларынын әсәрләре (шигырьләр, хикәяләр, шигырь формасында язылган тылсымлы әкиятләр, повестьлар); балалар әдәбияты классикларынын әсәрләре (шигырьләр, хикәяләр, әкиятләр, әкияти повестьлар); күпмилләтле Россиянең һәм чит илләрнең бүгенге көн әдәбияты классиклары әсәрләре (шигырьләр, хикәяләр, әкиятләр, әкияти повестьлар). Төрле төрдәге китаплар: тарихи, маҗаралы, фантастик, фәнни-популяр, белешмә-энөиклопедик әдәбият; Балалар матбугаты басмалары (балалар журналы).

Башлангыч белем бирү баскычында укучылар икенче (төп) баскычта белем алуга әзерләнә, балаларга кирәкле әдәби һәм гомумкуьтура нигезләре бирелә.

**Укучы өйрәнәчәк:**

--текст белән эшләргә; кирәкле мәгълүматны аерып алырга һәм аны төрле уку максатларында файдаланырга; китап белән эшли белергә һәм берничә мәгълүмати чыганак белән берьюлы эшләргә; сүзлекләр, басма матбугат, китапханә фонды белән эшләргә;

--әдәбиятның – сүз сәнгате булуын һәм гомуми сәнгатьнең бер төре икәнлеген аңларга;